**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

«22» 08 2022 ел Яр Чаллы ш. № 68

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча Әҗмәкәй авылында халык тыңлауларын үткәрү урынын күчерү турында (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 8 августындагы 64 номерлы карарына өстәмә рәвештә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 31 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн\2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 8 августындагы 64 номерлы карарына өстәмә рәвештә

**КАРАР БИРӘМ**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча Әҗмәкәй авылында халык тыңлауларын үткәрү урынын, клуб бинасының авария хәлендә булуына бәйле рәвештә, Үзәк ур., 35А адресы буенча урнашкан клуб бинасыннан Тукай ур., 3А адресы буенча фельдшер-акушерлык пунктына күчерергә.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Әҗмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше секторы мөдире О. А. Никитинага йөкләргә.

Район Башлыгы Ф. М. Камаев